КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 15 май, 282 нче; 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 205 нче; 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче; 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче; 2020 ел, 2 март, 155 нче; 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 70 нче; 2023 ел, 30 март, 380 нче; 2023 ел, 2 ноябрь, 1410 нчы; 2023 ел, 29 декабрь, 1741 нче; 2024 ел, 27 февраль, 100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

Илнур Мәхмүт улы Гариповның вазыйфа исеменә «(килешү буенча)» сүзләрен өстәргә;

конкурс комиссиясе составыннан А.М.Фроловны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Дамир Фәрит улы Шәйдуллинны кертергә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1277 нче
карары редакциясендә)

Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшли торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс төркемнәре

| Төркемнәр | Муниципаль берәмлек исеме | 2024 елның 2 ноябренә территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | Заявкаларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I төркем – шәһәр округлары | Казан шәһәре | 78 | 39 |
| | Яр Чаллы шәһәре | 78 | 39 |
| | Барлыгы | 156 | 78 |
| II төркем – халкы 60 мең кешедән күбрәк булган шәһәр җирлекләре | Әлмәт шәһәре | 36 | 18 |
| | Алабуга шәһәре | 18 | 9 |
| | Зеленодольск шәһәре | 4 | 2 |
| | Лениногорск шәһәре | 13 | 7 |
| | Түбән Кама шәһәре | 27 | 14 |
| | Чистай шәһәре | 8 | 4 |
| | Барлыгы | 106 | 54 |
| III төркем – халкы 60 мең кешегә кадәр булган шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлекләре | Әгерҗе шәһәре | 7 | 4 |
| | Азнакай шәһәре, Азнакай муниципаль районы составына керә торган Актүбә шәһәр тибындагы поселогы | 17 | 9 |
| | Алексеевск муниципаль районы составына керә торган Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы | 3 | 2 |
| | Арча шәһәре | 5 | 3 |
| | Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 25 | 13 |
| | Балтач муниципаль районы составына керә торган Балтач шәһәр тибындагы поселогы | 1 | 1 |
| | Буа шәһәре | 6 | 3 |
| | Чүпрәле муниципаль районы составына керә торган Иске Чүпрәле авыл җирлеге | 1 | 1 |
| | Алабуга муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 15 | 8 |
| | Зәй шәһәре | 13 | 7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы | 6 | 3 |
| | Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган барлык шәһәр һәм авыл җирлекләре | 21 | 11 |
| | Кукмара шәһәре | 4 | 2 |
| | Лаеш шәһәре һәм Лаеш муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 29 | 15 |
| | Мамадыш шәһәре, Мамадыш муниципаль районы составына керә торган Красная Горка авыл җирлеге | 9 | 5 |
| | Менделеевск шәһәре | 5 | 3 |
| | Минзәлә шәһәре | 5 | 3 |
| | Түбән Кама муниципаль районы составына керә торган Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | 3 | 2 |
| | Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 13 | 7 |
| | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы | 9 | 5 |
| | Сарман муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 3 | 2 |
| | Болгар шәһәре | 1 | 1 |
| | Тәтеш шәһәре | 5 | 3 |
| | Тукай муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 6 | 3 |
| | Ютазы муниципаль районы составына керә торган Урыссу шәһәр тибындагы поселогы | 10 | 5 |
| | Барлыгы | 222 | 121 |
| Барысы | | 484 | 253 |

___